**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«10» ноябрь 2021 ел** **№ 283**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының иҗтимагый торак комиссиясе турында» 2015 елның 18 маендагы 114 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының иҗтимагый торак комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (16.01.2017 №3, 29.06.2017 №174; 25.05.2018 №116, 06.02.2020 №38, 31.08.2020 №226, 21.09.2020 №247, 18.01.2021 №4, 28.06.2021 №144 карарлар редакциясендә)

«Азнакай шәһәрендә махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе турында һәм муниципаль махсуслаштырылган торак фондында хезмәт урыннары бирелә торган гражданнар категорияләрен билгеләү турында» 2006 елның 13 октябрендәге 48-8 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карары нигезендә карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының иҗтимагый торак комиссиясе турында» 2015 елның 18 маендагы 114 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының иҗтимагый торак комиссиясе турындагы нигезләмәгә (16.01.2017 №3, 29.06.2017 №174; 25.05.2018 №116, 06.02.2020 №38, 31.08.2020 №226, 21.09.2020 №247, 18.01.2021 №4, 28.06.2021 №144 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.1 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац белән тулыландырырга:

« - предприятие, учреждение, оешма вәкилләре катнашында хезмәт торак урынын хосусыйлаштыру турындагы гаризаны карау.».

1.2. 4.3 пунктны киләсе эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга:

«Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктындагы сигезенче абзацы буенча беркетмәдә хосусыйлаштыру мөмкинлеге турында йә торак урынны хосусыйлаштырудан баш тарту турында комиссия бәяләмәсе чагылдырыла.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында " түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары О. Н. Газизова